**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 апрель № 301

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 июнь, 542 нче, 2013 ел, 4 июль, 477 нче, 2014 ел, 26 апрель, 270 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«2015 елда югары белеме булган, 2015 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына эшкә килгән, яки башка торак пунктыннан Татарстан Республикасының авыл торак пунктына яисә эшчеләр поселогына эшкә күчеп килгән һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килешү төзегән 45 яшькәчә медицина хезмәткәрләренә (алга таба – медицина хезмәткәрләре) бер медицина хезмәткәренә 500,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртипләрен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 июль, 477 нче, 2014 ел, 26 апрель, 270 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тәртибендә:

1 пунктта «35» саннары «45» саннарына, «2011 – 2014 елларда» сүзләрен «2015 елда» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карар белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибендә:

1 пунктта «35» саннары «45» саннарына, «2011 – 2014 елларда» сүзләрен «2015 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 һәм 4 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

5 пунктта «2013 – 2014 елларда» сүзләрен «2015 елда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\301.doc